КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 12 апрель г.Казань № 348

Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен җир кишәрлеген һәм анда урнашкан күчемсез мөлкәт объектларын тартып алу турында

«Вознесенский тракты. Казан шәһәре муниципаль берәмлеге һәм Татарстан Республикасының Питрәч муниципаль районы территориясендә Җиңү проспектыннан «Волга» М-7 автомобиль юлына кадәр участок төзү» төбәк әһәмиятендәге автомобиль юлын төзү максатларында, Россия Федерациясе Җир кодексының VII бүлегендәге 49 статьясы, VII[1] бүлеге, Россия Федерациясе Граждан кодексының 279 һәм 281 статьялары, Татарстан Республикасы Җир кодексының 3 статьясы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының территориаль планлаштыру схемасын раслау турында» 2011 ел, 21 февраль, 134 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының территориаль планлаштыру схемасы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының, "Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы каршындагы Татарстан юл-транспорт комплексын (алга таба - Баштатюлтранс) тоту һәм үстерүнең төп идарәсе” дәүләт казна учреждениесенең «Вознесенский тракты. Казан шәһәре муниципаль берәмлеге һәм Татарстан Республикасының Питрәч муниципаль районы территориясендә Җиңү проспектыннан «Волга» М-7 автомобиль юлына кадәр участок төзү» төбәк әһәмиятендәге автомобиль юлын төзү максатларында Татарстан Республикасы, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге, Казан шәһәре, Совет районы, Вознесенский п., Үзәк урам, 1а йорт(алга таба - алына торган мөлкәт) адресы буенча күчемсез мөлкәт объектлары территориясендә урнашкан һәм 585 кв.метр мәйданлы 16:50:270245:7 кадастр номерлы М.Х.Шаһиева милкендә булган (алга таба - алына торган мөлкәт милекчесе) җир кишәрлеген (алга таба - алына торган мөлкәт) Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен алу турында тәкъдимен кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына түбәндәгеләрне законнар белән билгеләнгән тәртиптә тәэмин итәргә:

10 көн эчендә:

бу карарны үзенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыруны;

бу карарны Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең муниципаль хокукый актларын рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) өчен билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгаруны;

бу карарның күчермәләрен алына торган мөлкәт милекчесенә, «Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Федераль кадастр палатасы» федераль дәүләт бюджет учреждениесенең Татарстан Республикасы буенча филиалына, Татарстанның юл-транспорт идарәсенә җибәрүне;

алына торган мөлкәт өчен түләү күләме билгеләнгәннән соң 30 көн эчендә, Татарстанның юл-транспорт идарәсе белән берлектә, Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен мөлкәтне алу турында килешү (алга таба – килешү) әзерләүне һәм аны алына торган мөлкәт милекчесенә җибәрүне;

килешү төзүне;

алына торган мөлкәт өчен түләү;

алына торган мөлкәткә Татарстан Республикасы милек хокукын дәүләт теркәве;

алына торган мулкәт милекчесе тарафыннан имза куелган килешү законнар белән билгеләнгән вакытта тапшырылмаган очракта, судка тиешле дәгъвалар бирүне.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин